Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

«21» сентябрь 2020 ел № 6

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 24 апрелендәге «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 69 номерлы карарына (2018 елның 13 июнендәге 75 номерлы, 2018 елның 14 ноябрендәге 93 номерлы, 2019 елның 28 маендагы 111 номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Уз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, муниципаль берәмлекләр башлыкларының айлык акчалата түләүләре күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарлары, депутатлар, Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " 2018 елның 28 июнендәге 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә

ашыручы муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, контроль-хисап органнары рәисләренең (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 17.10.2018 елдагы 940 номерлы, 29.12.2018 елдагы 1320 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " Бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 24 апрелендәге «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 69 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Иске Казиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 13 июнендәге 75 нче номерлы карары белән, 2018 елның 14 ноябрендэге 93 нче номерлы карары, 28.05.2019 ел, № 111 карары белэн кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.2 һәм 4.2 пунктларда,. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдэ «11 163,00» санын «11 498,00»санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Иске Казиле
авыл җирлеге башлыгы И.Х. Сагьдиев